**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.05.2023 елның 4 мае № 577

Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2024 елларга Кама Тамагы муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 07 октябрендәге 1003 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023елның 14 мартындагы 635-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «2020-2024 елларга Кама Тамагы муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 7 октябрендәге 1003 номерлы карары белән расланган «2020-2024 елларга Кама Тамагы муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәреш кертергә: 1.1. 3 бүлекне әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының "2020-2024 елларга Кама Тамагы муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү «муниципаль программасын раслау турында" 2021 елның 16 февралендәге 135 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 17 февралендәге 132 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Е.В. Сороковнинага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Баржанов

Кама Тамагы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2023елның 4
маендагы 577номерлы карарына
кушымта

## 3.ПРОГРАММАГА КАРАГАН ЧАРАЛАР

| № т/б | Чаралар исеме | Гамәлгә ашыру вакытлары | **Бюджет** | **2020** | **2021** | **2022** | **2023** | **2024** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру | 2020-2024 | МБ | 35001,0 | 30887,7 | 37330,7 | 39566,1 | 36986,6 |
| 2 | Массакүләм спорт өлкәсендә физик культура һәм спорт чаралары | 2020-2024 | МБ | 833,5 | 1653,5 | 1823,3 | 1182,3 | 688,1 |
| 3 | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алу | 2020-2024 | РБ | 151,05 | 171,9 | 170,0 | 179,4 | - |
| 4 | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында спорт резервын әзерләүче физкультура, спорт оешмалары яшь белгечләренә акчалата түләүләр. | 2020-2024 | РБ | 46,3 | 20,3 | 25,8 | 37,0 | - |
| 5 | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында спорт резервын әзерләүче физкультура, спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү. | 2020-2024 | РБ | 43,4 | 35,2 | 87,3 | 200,0 | - |
| 6 | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә физик культураны, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны спорт объектларының террорчылыкка каршы саклануын тәэмин итү өчен җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өлешендә гамәлгә ашыру. | 2020-2024 | РБ | - | 246,6 | 1534,5 | - | - |
| | | | МБ | - | 0 | 15,5 | - | - |
| 7 | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә физик культураны, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенә модульле чаңгы базасының оператив идарәсе хокукында беркетелүгә бәйле рәвештә муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итү күләмен арттыру өлешендә. | 2023-2025 | РБ | - | - | - | 1025,0 | |